# "Казан силикат стена материаллары заводы" ҖЧҖ

Төзелеш материаллары (силикат кирпеч, вак тишекле бетон блоклар) җитештерү

www.kzssm.ru

## Казан силикат стена материаллары заводы - ул Татарстан Республикасында һәм Идел буе федераль округында иң зур төзелеш материаллары җитештерүче.


- Заводның проект куәте елына 224,2 млн данә шартлы кирпеч һәм 100 мең кубометр вак тишекле блок тәшкил итә.
- Завод чыгарыла торган продукция ассортиментын даими рәвештә киңәйтү өстендә эшли. Бүгенге көндә җитештерү мәйданчыгында чыгарыла торган продукциянең гомуми номенклатурасы 50 төрдән артык эшләнмә хасил итә. Калынайтылган силикат кирпечтән тыш завод түбәндәгеләрне дә чыгара:
- рельефлы ярылган силикат кирпеч,
- 10 төскә (сары, кызыл, коңгырт, кара, соры, зәңгәр, яшел һ.б.) күләмен арттырып буялган төсле тышлагыч кирпеч,
- ак төсле куыш силикат кирпеч, өч куышлы силикат ташы, бүлге өчен силикат блоклар,
- вак тишекле бетоннан газ-бетон блоклары, төзелеш известе.

www.kzssm.ru

# Силикат кирпеч

- Силикат кирпеч - ныклы төзелеш материалы, алга таба автоклавта мул пар йогынтысында катырып, известь һәм ком нигезендә катнашмаларын ярымкоры килеш тыгызлау ысулы белән әзерләнә. Силикат кирпечнең башлангыч "табигый" төсе - ак. Атмосферага һәм селтегә чыдам пигментларны өстәгәндә төсле силикат кирпече барлыкка килә.
- Силикат кирпечнең сыйфатламаларын һәм үзлекләрен ГОСТ 379-2015 "Кирпеч, ташлар, блоклар һәм бүлге өчен силикат плитәләр. Гомуми техник шартлары" регламентлый.
- Сыйфатлы әзерләнгән эшләнмә ватык һәм ярык урыннары булмаган тигез турыпочмаклы формада була. Стандарт зурлыгы - 250*120*65. Нигездә бер ярым зурлыктагы калынлыкта (биеклектә) калынайтылган 88 мм чыгарыла.
- Төп сыйфатламалары буенча силикат кирпеч башка вак данәле стена төзү материалларыннан аерылмый, кайбер өлешләрендә өстен дә чыга:
- Ныклылыгы буенча түбәндәге маркаларда була: 100, 125, 150, 200 һәм 250.
- Кышкы салкынга чыдамлылыгы F-50-75, ел дәвамында температура үзгәрешләрен яхшы кичерә, ныклы үзлекләрен югалтмыйча 100 елга кадәр хезмәт итә.
- Менә дигән тавыш изоляциясе.
- "Фонламый" - табигый радионуклидлар активлыгы бик түбән (28,8 Бк/кг).

Силикат кирпеч – экологик чиста продукт. Известь, ком һәм су – аны тәшкил итүчеләр. Силикат кирпеч һәм блоклар – ныклы, арзанлы, геометрик зурлыклары буенча төгәл төзелеш материалы. Алга киткән илләрдә киң таралган.










www.kzssm.ru

**Газ-бетоннан эшләнгән блоклар тышкы, эчке стеналарны, чагыштырма һава дымлылыгы 75% артмаган һәм агрессив булмаган тирәлектә подвалларның һәм биналарның стеналарын һәм бүлгеләрен өю өчен билгеләнгән. Чагыштырма һава дымлылыгы 75% артып киткәндә тышкы газ-бетоннан эшләнгән стеналарның эчке өслекләрендә пар изоляцияле торган каплама булырга тиеш.**

**Газ-бетон** (вак тишекле бетон) – ул экологияле, җылы һәм экономияле, эшкәртүдә җиңел!

**Экологик**

- вак тикшекле бетон экологик чиста органик булмаган төзелеш материалы булып тора.
- ул череми, янмый, искерми һәм агулы матдәләр бүлеп чыгармый.
- алманнарның югары технологияле автоматлаштырылган "W+K" линиясендә экологик чиста, кыйммәтле булмаган чималдан (ком, известь, цемент) әзерләнә.
- әлеге материалдан эшләнгән корылмаларда микроклимат бары тик агач йортлардагы микроклиматтан гына калыша.

**Җылы**

- газ-бетонның җылылык изоляцияләү буенча югары күрсәткечләренә үзара бәйләнмәгән вак тишекләрнең күп булуы хисабына ирешелә.
- вак тишекле бетонның җылы үткәрүчәнлеге кирпечкә караганда 5 мәртәбә кимрәк (сынаулар белән расланды).

**Тиз**

- үзенең җылылык-техник, ныклылык үзлекләре һәм типик зурлыклары аркасында төзелмәләрне монтажлау тизлеге арта.
- газ-бетоннан стена өйгәндә башка материаллардан бина төзү белән чагыштырганда 2-3 тапкырга азрак хезмәт сарыф ителә.

**Экономияле**

- чагыштырма авырлы аз булуга бәйле рәвештә, фундаментка булган басым азая, бу исә заказчыларның чыгымнарын шактый киметә.
- газ-бетонның җылылыкны бер урында туплау үзлекләре биналарда уңайлылык арттыруга ярдәм итә һәм җылытканда шактый янга калдыру мөмкинлеген бирә.
- башка төзелеш материаллары белән чагыштырганда вак тишекле бетонның чагыштырма авырлыгы азрак булу хисабына, заказчының транспорт чыгымнары шактый кими.

Автоклав катырыла торган газ-бетон (вак тишекле бетон) - ныклы һәм күзәнәкле төзелеш материалы, агач һәм таш үзлекләрен үзендә органик рәвештә берләштерә.



www.kzssm.ru

# Безнең продукция объектлары



Балалар бакчасы



Гимназия



Торак комплексы




Хосусый коттедж

www.kzssm.ru

# "КССМЗ" ҖЧҖ элемтәләре

- №1 эш тармагы, 420036, Татарстан Республикасы, Казан ш., Тэц ур., 3 (кирпеч)
- № 2 эш тармагы, 420051, Татарстан Республикасы, Казан ш., Автосервис ур., 5 (кирпеч, газобетон)
- Телефоннар:

+7 (843) 5-707-909 Сату бүлеге
+7 (843) 5-719-259 Өземтә
Email: info@kzssm.ru